СОВЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** с.Старое Дрожжаное **КАРАР**

2024 елның 29 мае № 38/2

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында» Федераль законның 12 статьясына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 12 декабрендәге 594-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2020 елның 30 гыйнварындагы 42/4 номерлы карары белән (03.06.2020 № 45/4, 12.11.2020 № 3/6, 05.02.2021 № 6/4, 16.08.2021 № 11/3, 13.02.2023 № 25/1, 20.06.2023 № 29/6, 17.08.2023 № 30/3, 09.11.2023 № 32/5, 14.12.2023 № 33/5 редакциясендә) расланган Чүпрәле муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1) 8 статьяның 1 пунктына** түбәндәге эчтәлекле **12 пункт** өстәргә:

«12) яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 15_2 статьясында каралган анкетадагы, яллаучы вәкиленең (эш бирүченең) карары буенча үзгәргән белешмәләрдән башка, белешмәләрнең үзенә мәгълүм булган үзгәрешләр турында язма рәвештә хәбәр итәргә (алга таба - анкетадагы белешмәләр).»;

**2) 11 статьяның 1 пунктының 8 пунктчасын** түбәндәге редакциядә бәян **итәргә:**

«8) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм (яисә) аны үткән вакытта ялган документлар һәм (яисә) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачаулый торган чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәүне раслаучы, яисә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә комачаулый торган чикләүләрне, тыюларны һәм (яисә) таләпләрне үтәмәүне раслаучы ялган мәгълүматлар тапшыру;»;

**3) 13 статьяда:**

**а) 3 нче пунктның 2 нче пунктчасын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 15_2 статьясында каралган анкета;»;

**б) 4 пунктка** түбәндәге эчтәлекле **абзац** өстәргә:

«Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфасын биләгәндә хезмәт шартнамәсе төзү алдыннан Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә конкурс үткәрелә.»;

**4) 20 статьясының 2 пунктында:**

**а) 11 пунктчаны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11) муниципаль хезмәткә кергәндә һәм муниципаль хезмәткәрләргә узган вакытта граждан тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрне тикшерүне оештыру һәм үткәрү;»;

**б)** түбәндәге **эчтәлекле 11_1** пунктча өстәргә:

11_1) дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматларга билгеләнгән рәвешкә рөхсәт кәгазе рәсмиләштерү;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районы Башлыгы, Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе М.Р. Гафаров